ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2020 п.г.т.Алексеевское № 65

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасының территориаль өстәмә системасының муниципаль звеносы турында» 2018 елның 17 маендагы 127 номерлы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм кайбер актларның аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 28 декабрендәге 1934 номерлы карары нигезендә карар чыгару максатларында

**карар кылам:**

1. 9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм авария-коткару формированиеләрен гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә җәлеп итү «Һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында» Федераль законның 13 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла».

2. 1 нче кушымтаның 2 пунктында «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә» сүзләрен «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**